КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 август г.Казань № 778

Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турында нигезләмәне расларга
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 9 август, 778 нче карары белән расланды

## Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турында нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 2019 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 ел, 11 июнь, 563 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 05 март, 158 нче карары нигезендә эшләнгән.

2. Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләүне Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, мәгариф оешмалары, коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлектә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы гамәлгә ашыра.

4. Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү түбәндәге юнәлешләр буенча гамәлгә ашырыла:

гражданлык, ватанпәрвәрлек, гореф-гадәтләрнең дәвамчанлыгы, илебез тарихына хөрмәт, Россия Федерациясе халыкларының тарихи, милли һәм башка традицияләренә таяну;

яшьләр арасында милләтара (этникара) һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, яшьләр берләшмәләре эшчәнлегендә экстремизм күренешләрен профилактикалау һәм кисәтү;

авыр тормыш хәлендә калган яшь гражданнарга, яшь гражданнар арасыннан инвалидларга, шулай ук ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга ярдәм итү;

яшьләр инициативаларына ярдәм итү;

яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый эшчәнлеккә ярдәм итү;

яшьләрнең буш вакытын, ялын, аларны савыктыруны оештыру, физик культура, спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, яшьләрнең сәламәт яшәү рәвешенә ярдәм итү;

яшьләргә социаль хезмәтләр күрсәтү;

яшьләрнең, яшь гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүгә ярдәм итү;

яшь гаиләләргә ярдәм итү;

яшьләрнең белем алуына, яшьләрнең фәнни, фәнни-техник эшчәнлегенә булышлык күрсәтү;

яшьләр белән эшләү буенча белгечләр әзерләүне оештыру;

сәләтле яшьләрне ачыклау, озатып йөрү һәм аларга ярдәм итү;

остазлык институтын үстерү;

яшьләрнең хезмәт һәм эш белән тәэмин ителеш өлкәсендә гарантияләрне тәэмин итү, яшь гражданнарны эшкә урнаштыруга ярдәм итү, шул исәптән студентлар отрядлары, яшь белгечләрне һөнәри үстерү юлы белән;

яшьләргә эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү һәм ярдәм итү;

яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә ярдәм итү;

яшьләрнең ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуына ярдәм итү;

яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлеккә ярдәм итү;

яшьләрнең хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү;

фән, сәнгать, әдәбият әсәрләрен һәм яшьләрнең гражданлык тәңгәллеген һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрен ныгытуга юнәлдерелгән башка әсәрләрне иҗат итү һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга ярдәм итү;

яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча фәнни-аналитик тикшеренүләр үткәрү.

5. Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәте өлкәсендә төп юнәлешләр буенча республика программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән әхлакый кыйммәтләрне тәрбияләүгә юнәлдерелгән, яшьләрдә татар халкының һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның традицияләренә, гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә карата кызыксыну һәм хөрмәт формалаштыру;

яшьләр сәясәте өлкәсендә төп юнәлешләр буенча муниципаль программаларны эшләүдә методик ярдәм күрсәтү;

яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә методик ярдәм күрсәтү;

балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары реестрында торучы балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмалары турында мәгълүматларның дөреслеге, актуальлеге һәм тулылыгы өчен төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру;

яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме чараларын гамәлгә ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

яшьләр сәясәте инфраструктурасын булдыру һәм үстерү;

яшьләр сәясәте инфраструктурасыннан нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны мониторинглау;

яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләрен һөнәри үстерү чараларын үткәрү, яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренә аттестация үткәрү;

балалар һәм яшьләр ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру;

яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрендә, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда тәрбия эшенең төрле рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү;

дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне фәнни, аналитик, методик тәэмин итү системасын оештыру һәм камилләштерү;

яшьләрнең асоциаль тәртибен профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

дәүләт ярдәменнән файдаланучы яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең республика реестрын булдыру һәм алып бару;

яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, физик затлар эшчәнлегенә һәм аларның инициативаларына грант ярдәме;

яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт казна, бюджет һәм автоном учреждениеләрен гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларының тәрбия эше структураларының эшен координацияләү өчен шартлар формалаштыруда катнашу;

ирекле лек өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу (волонтерлык);

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне гамәлгә ашыру;

яшьләр сәясәте өлкәсе мәсьәләләре буенча закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар проектларын эшләү.

______________________